**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.06.2016 № 348

г.Казань

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 13 июлендә теркәлде, № 3425

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү
өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген)
башкару дәүләт функциясен үтәү буенча
административ регламентын раслау турында

“Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” 28 декабрь, 2013 ел, № 442-ФЗ Федераль законны һәм “Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 18 декабрь, 2014 ел, № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру максатларында **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкару дәүләт функциясен үтәү буенча кушымта итеп бирелүче административ регламентын (алга таба – Административ регламент) расларга.

2. Билгеләргә:

Административ регламентның 1.2 пунктының өченче абзацы, 1.8.2 пунктчасының тугызынчы һәм ундүртенче абзацлары, 1.9.1 пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацлары, 1.11 пунктының дүртенче абзацы, 2.3.3 пунктчасы, 5.4.4.4 пунктчасының икенче абзацы 2016 елның 1 июленнән көчләренә керә;

Административ регламентның 1.8.3 пунктчасының унынчы һәм унберенче абзацлары 2017 елның 1 гыйнварыннан көчләренә керә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль хезмәт күрсәтү сыйфатын идарә итү бүлегенә: Административ регламентның нигезләмәләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Ю.И.Әбдриевага йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының от 21.06.2016 ел, № 348 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкару дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкару дәүләт функциясен үтәү буенча бу административ регламенты (алга таба – Административ регламент) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкаргандагы административ процедуралары (гамәлләре) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең атамасы: “Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (алга таба – дәүләт функциясе).

1.2. Дәүләт функциясен үтәүче булып Министрлык тора.

Дәүләт функциясен турыдан-туры үтәү Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәрләре – Министрлыкның Социаль хезмәт күрсәтү сыйфатын идарә итү бүлеге хезмәткәрләре (алга таба – Бүлекнең вазыйфаи затлары) тарафыннан башкарыла.

Тиешле мәгълүматны, 2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контролен

(күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында" 28.04.2015 ел, № 415 карарына туры китереп, тикшерүләрнең бердәм реестрына кертү Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.

1.3. Дәүләт функциясен үтәгәндә, Министрлык Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары (алга таба – прокуратура органнары), Россия Федерациясенең аккредитация турындагы законына туры китереп, илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләнгән экспертлар һәм эксперт оешмалары (алга таба – эксперт оешмалары), дәүләт хакимияте органнары, юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итә.

1.4. Дәүләт функциясен үтәүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге:

2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2013 елның 28 декабрендәге "Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында" № 442-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 442-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52, 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2011 елның 4 маендагы "Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында" № 99-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 99-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2006 елның 27 июлендәге "Персональ мәгълүматлар турында" № 152-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе

законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1999 елның 30 мартындагы “Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында” № 52-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 52-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2000 елның 2 гыйнварындагы “Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында” № 29-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 29-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, № 2, 150 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү турында” 2006 елның 2 маендагы № 59-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Аларга карата планлы тикшерүләр билгеләнгән ешлыкта уздырыла торган юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан сәламәтлек саклау өлкәсендә, мәгариф өлкәсендә һәм социаль өлкәдә башкарылучы эшчәнлек төрләре исемлеген раслау турында” 23.11.2009 ел, № 944 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 48, 5824 ст.; 2011, № 4, 614 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны тикшерүләр уздыруның еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында” 30.06.2010 ел, № 489 карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 489 карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” 28.04.2015 ел, № 415 карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 415 карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2925 ст.);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Социаль

хезмәтләр күрсәтү хакындагы килешүнең үрнәк формасы турында, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы формасы турында” 2014 елның 10 ноябрендәге № 874н боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының № 874н боерыгы) (Российская газета, 2015, 12 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” Федераль законның нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында” 30.04.2009 ел, № 141 боерыгы (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы) (Российская газета, 14.05.2009, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 18 декабрь, 2014 ел, № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законы (Республика Татарстан, 2014, 20 декабрь);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 388 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкаруны оештыру тәртибен раслау турында” 25.11.2014, № 909 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2014, № 93, 2872 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелү тәртибен раслау

турында” 31.12.2014 ел, № 1100 карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелү тәртибе (алга таба – Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибе) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2015, № 23-24, 0785 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелү тәртибен раслау турында” 31.12.2014 ел, № 1101 карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелү тәртибе (алга таба – Ярым стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары белән расланган тәртибе) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2015, № 34-35, 1171 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең өйдәге формасында социаль хезмәтләр күрсәтелү тәртибен раслау турында” 29.12.2014 ел, № 1053 карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең өйдәге формасында социаль хезмәтләр күрсәтелү тәртибе (алга таба – Өйдәге формада социаль хезмәтләр күрсәтүнең № 1053 ТР МК карары белән расланган тәртибе) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2015, № 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан

Республикасында социаль хезмәтләр алучыларның регистрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе турында” 23.12.2014 ел, № 1012 карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр алучыларның регистрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе (алга таба – Регистрны формалаштыру һәм алып баруның № 1012 ТР МК карары белән расланган тәртибе) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2015, № 3, 0093 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен һәм аны түләтү тәртибен раслау турында” 29.11.2014 ел, № 927 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2014, № 91-92, 2850 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләре үтәлүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” 31.12.2012 ел, № 1192 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2013, № 7, 2850 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары булып, оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы юридик затлар һәм (яки) шәхси эшкуарлар (алга таба – социаль хезмәт күрсәтүчеләр) тора.

1.6. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең үз эшчәнлекләре барышында оешмаларның билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу өлкәсендә, социаль хезмәтләрнең күләменә, сыйфатына, аларны күрсәтү тәртибенә һәм шартларына № 442-ФЗ Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аңа туры китереп кабул ителүче

бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары белән гамәлгә кертелгән мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәве, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи заты күрсәтмәләрен үтәве, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерелүне булдырмау буенча, китерелгән андый зыянның нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар уздыруы тора.

1.7. Дәүләт функциясен үтәү Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан, социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрне тикшерүләрнең түбәндәге төрләрен (алга таба – тикшерүләр) үткәрү юлы белән башкарыла:

план буенча урынга барып тикшерү;

планнан тыш (урынга барып, документларны) тикшерү.

1.8. Тикшерү үткәргәндә, Министрлыкның вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары:

1.8.1. Министрлыкның тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары, тикшерү үткәргәндә, түбәндәгеләргә хокуклы:

тикшерү үткәрү максатыннан, социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан эшчәнлекләрен башкарганда файдаланыла торган территорияләргә, биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, бүлмәләргә барырга (хезмәт итү таныклыгын һәм Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының (алга таба – министр) (министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турында боерыгы (әмере) (алга таба шулай ук – тикшерү үткәрү турында боерык (әмер)) күчермәсен күрсәтеп);

тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча документлар һәм материаллар, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча язмача аңлатмаларын сорап алырга;

социаль хезмәт күрсәтүләрне алучылар белән, социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле белән тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча әңгәмәләр үткәрергә;

аңа карата тикшерү үткәрелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүче белән

граждан-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм тикшерелүче затларның аффилирланган затлары булып тормаучы экспертларны, эксперт оешмаларын урынга барып тикшерү үткәрүгә җәлеп итәргә.

1.8.2. Тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар, тикшерү үткәргәндә, түбәндәгеләргә бурычлы:

мәҗбүри таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм аңа юл куймау буенча Россия Федерациясе законына, Татарстан Республикасы законына туры китереп бирелгән вәкаләтләрен вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

Россия Федерациясе законын, Татарстан Республикасы законын, эшчәнлекләре тикшерелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

тикшерү билгеләүгә тәңгәл рәвештә, тикшерүне министрның (министр урынбасарының) аны уздыру турында боерыгы (әмере) нигезендә үткәрергә;

тикшерүне бары тик хезмәт йөкләмәләрен үтәгән вакытта гына уздырырга; урынга барып тикшерүне бары тик эш буенча куллана торган таныклыкларын, министрның (министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турында боерыгы (әмере) күчермәсен күрсәтеп кенә үткәрергә, ә урынга барып, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зыян китерелү (зыян китерелү куркынычы туу), шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү (барлыкка килү куркынычы туу) фактлары буенча планнан тыш тикшерү үткәргән очракта, шулай ук тикшерү үткәрүнең прокуратура органнары белән килештерелгәнлеге турында документ күчермәсен дә күрсәтергә;

социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә шунда булырга һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламаска;

социаль хезмәтләр күрсәтүченең тикшерү үткәргәндә катнашучы җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүмат һәм документларны бирергә;

социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре, шул исәптән тикшерү акты белән таныштырырга;

социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга, аларны тапшыру Россия Федерациясе законы белән күздә тотылмаган документлар һәм (яки) мәгълүмат таләп итмәскә;

ачыкланган хокук бозу фактлары буенча күрелүче чараларны билгеләгәндә, әлеге чараларның хокук бозулар авырлыгына тәңгәл килүен, аларның кешеләрнең гомере, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), дәүләт иминлеге өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу өчен ихтимал куркынычын исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска;

аларга карата социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр шикаять белдергәндә, үз гамәлләренең нигезлелеген Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә дәлилләргә;

тикшерү үткәрүнең № 294-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән срокларын сакларга;

урынга барып тикшерү үткәрүне башлау алдыннан, социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиленең үтенече буенча, аларны бу Административ регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

тикшерүләрне исәпкә алу журналына, социаль хезмәтләр күрсәтүчедә ул булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында язып куярга.

1.8.3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларның, тикшерү үткәргәндә, түбәндәгеләргә хакы юк:

әгәр андый таләпләр Министрлык вәкаләтләренә кермәсә, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

СССР һәм РСФСРның башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары белән гамәлгә кертелгән һәм Россия Федерациясе законына туры килмәүче таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган хокукый актлар белән гамәлгә кертелгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

аны үткәргәндә, социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, урынга барып, план буенча яки планнан тыш тикшерү үткәрергә (андый тикшерүне гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зыян китерелү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу нигезе буенча үткәрү очрагыннан гайре);

тикшерү объектлары булып тормаучы яки тикшерү предметына кагылышы булмаган документлар, мәгълүматлар бирүне таләп итәргә, шулай ук андый документларның төп нөсхәләрен тартып алырга;

Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очраклардан гайре, тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт итү сере, закон белән саклanылучы бүтән сер булып торучы мәгълүматны таратырга;

тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттырырга;

контроль чараларын алар хисабыннан уздыру турында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә;

дәүләтнең бүтән органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булып, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән рөхсәт итүче документларны да кертеп, документлар һәм (яки) мәгълүмат бирүне таләп итәргә;

Россия Федерациясе законы таләпләренә туры китереп, элегрәк бирелгән һәм (яки) дәүләтнең яки муниципалитетның мәгълүмат системаларында,

реестрларында һәм регистрларында торган мәгълүматны бирүне социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрдән таләп итәргә.

1.9. Аларга карата социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чаралары күреләә торган затларның хокуклары һәм бурычлары:

1.9.1. Социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәрелгәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

тикшерү үткәрелгәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

Министрлыктан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагылышы булган һәм аны бирү № 294-ФЗ Федераль закон белән күздә тотылган мәгълүматны алырга;

Министрлык дәүләтнең бүтән органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан алар карамагында торучы документлар һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алган әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында сорап алынучы документлар һәм (яки) мәгълүматны Министрлыкка үз инициативасы белән тапшырырга;

тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышканлыгы, алар белән, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве хакында тикшерү актына язарга;

Министрлыкның вазыйфаи затларының, тикшерү үткәргәндә, социаль хезмәтләр күрсәтүченең вазыйфаи затларының хокуклары бозылуга сәбәп булган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата административ һәм (яки) суд тәртибендә, Россия Федерациясе законнарына туры китереп, шикаять белдерергә;

тикшерүдә катнашуга Эшкуарларның хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләт иясен яисә Эшкуарларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы

вәкаләт иясен чакырырга;

социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын гамәлгә ашырганда, Министрлыкның вазыйфаи затларының Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә законсыз дип танылган гамәлләре (гамәл кылмаулары) аркасында китерелгән зыянны каплауга.

1.9.2. Социаль хезмәтләр күрсәтүченең житәкчесе яки вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәрелгәндә түбәндәгеләргә бурычлы:

Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан соралучы документлар һәм материалларны, шулай ук тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча телдән һәм язмача аңлатмалар бирергә;

Министрлыкның вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларының социаль хезмәтләр күрсәтүче үз эшчәнлегендә файдалана торган биналарга, бүлмәләргә, корылмаларга каршылыксыз керә алуын тәэмин итәргә;

шунда булырга яки социаль хезмәтләр күрсәтүченең мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм уздыруга җаваплы вазыйфаи затларының яки вәкаләтле вәкилләренең шунда булуын тәэмин итәргә;

дәлилле рәсми мөрәҗәгать алынганда, аны алган көннән башлап ун эш көне эчендә, рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны Министрлыкка җибәрергә.

1.10. Дәүләт функциясен үтәүнең нәтиҗәсе булып социаль хезмәтләр күрсәтүче мәҗбүри таләпләр бозылуның булуын яки булмавын ачыклау тора.

1.11. Дәүләт функциясен үтәү шулар белән тәмамлана торган юридик фактлар булып түбәндәгеләр тора:

тикшерү акты (тикшерү актының РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган типовой формасы нигезендә);

тикшерүләрне исәпкә алу журналына (ул булганда) урынга барып уздырылган тикшерү турында язып кую (тикшерүләрне исәпкә алу журналының формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган);

№ 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 415 карарына туры китереп, тикшерүләрнең бердәм реестрына шул хакта кертелгән мәгълүмат;

мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта:

мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә);

РФ АХБКның 19.5 статьясының 1 өлеше, 19.6, 19.7 статьялары белән күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә.

Дәүләт функциясен үтәү өчен нигез булып Министрлыкка гражданнарның, шул исәптән оешмаларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – гариза бирүче) мәгълүмат керү торган очракта, гариза бирүчегә дәүләт функциясен үтәүнең нәтиҗәләре буенча № 59-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. Дәүләт функциясен үтәү тәртибенә таләпләр

2.1. Дәүләт функциясен үтәү турында мәгълүмат бирү тәртибе:

2.1.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Волгоград ур., 47 й., тел. (843) 557-20-01, факс 520-92-87.

Министрлыкның эш графигы: шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш көн саен, 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькәчә төшке ашка бүленеп, 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә (җомга көннәрендә – 16.45 сәгатькәчә).

Министрлыкның урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре (алга таба – “Интернет” челтәре) аша:

Министрлыкның рәсми сайтында;

Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефоннан);

Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

2.1.2. Дәүләт функциясен үтәү буенча белешмә мәгълүмат Бүлекнең вазыйфаи затлары тарафыннан (843) 557-20-53; 557-21-31 телефоннары аша бирелә.

2.1.3. Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайты адресы: http://mtsz.tatarstan.ru.

Электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru.

Министрлыкка дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420044, Казан ш., Волгоград ур., 47 й.

2.1.4 Дәүләт функциясе һәм аны үтәү тәртибе турында мәгълүмат Бүлекнең вазыйфаи затлары тарафыннан бирелә:

- шәхсән кабул итү кысасында турыдан-туры;

- язмача (бу Административ регламентның 2.1.3 пунктында күрсәтелгән реквизитлар буенча почта аша мөрәҗәгать иткәндә);

- электрон элемтә яки телефон элемтәсе ярдәмендә.

Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң кичекмәстән бирелә, язмача мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгатькә җавап, тиңдәшле рәвештә, күрсәтелгән почта адресына яки электрон адреска әлеге мөрәҗәгать Министрлыкта теркәлгән көннән алып, календарь көннәрендә исәпләнүче утыз көнлек срокта җибәрелә.

2.1.5. Министрлыкның рәсми сайтында, мәгълүмат стендларында Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

1) урнашкан урыннары, элемтәгә керү өчен телефоннары, “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтлары, электрон почта адреслары турында белешмәләр;

2) Россия Федерациясе законнарының, Татарстан Республикасы законнарының дәүләт функциясен үтәү тәртибенә кагылышлы төп нигезләмәләре турында мәгълүмат;

3) кушымталары белән бергә бу Административ регламентның тексты;

4) дәүләт функциясен үтәү барышы турында мәгълүмат;

5) дәүләт функциясен үтәүче вазыйфаи затларны карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерү тәртибе.

Мәгълүмат стендлары Министрлык бинасына урнаштырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан тора.

2.1.6. Бу Административ регламент турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтына (http://www.mert.tatarstan.ru) урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләре үтәлүнең административ регламентлары бердәм реестрына кертелә.

2.2. Дәүләт күзәтчелеге чараларын уздырган өчен юридик затлардан һәм шәхси эшкуарлардан түләү алуның рөхсәт ителмәве.

Дәүләт күзәтчелеге чараларын уздырган өчен, шул исәптән экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре өчен дә (аларны тикшерү үткәрүгә җәлеп иткән очракта) юридик затлардан һәм шәхси эшкуарлардан түләү алынмый.

2.3. Дәүләт функциясен үтәү срогы

2.3.1. Тикшерү үткәрү (документлар тикшерү дә, урынга барып та) срогы 20 эш көненнән артык була алмый.

Бер кече эшкуарлык субъектына карата, урынга барып, план буенча тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен бер елга илле сәгатьтән һәм бик кечкенә предприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

2.3.2. Катлаулы һәм (яки) озакка сузылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар, тикшерүләр үткәрү зарурлыгына бәйле гадәттән тыш очракларда, Министрлыкның урынга барып, план буенча тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә, урынга барып, план буенча тикшерү үткәрү срогы министр тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 20 эш көненнән дә артыкка түгел, кече предприятиеләргә карата – 50 сәгатьтән дә артыкка түгел, бик кечкенә предприятие өчен унбиш сәгатьтән дә артыкка түгел.

2.3.3. Кече эшкуарлык субъектына карата план буенча урынга барып тикшерү уздырганда, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында

документлар һәм (яки) мәгълүмат алу зарурлыгы очрагында, тикшерү уздыру министр (министр урынбасары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү өчен кирәкле срокка туктатылып торырга мөмкин, ләкин 10 эш көненнән дә артыкка түгел. Тикшерү үткәрүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда кече эшкуарлык субъектының территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, бүлмәләрендә, бүтән объектларында Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге тикшерүгә бәйле гамәлләре туктатып торыла.

2.3.4. Бер социаль хезмәтләр күрсәтүчене план буенча тикшерү өч елга бер тапкырдан ешрак уздырылмый.

Социаль хезмәтләрне яшәп торуны тәэмин итеп күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтүчене план буенча тикшерү ике елга бер тапкырдан ешрак уздырыла алмый.

2.4. Тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр.

2.4.1. Социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрне план буенча тикшерүләр министр (министр урынбасары) боерыгына (әмеренә) туры китереп, план буенча тикшерүләр уздыруның Министрлык тарафыннан төзелә торган еллык планнары (алга таба – еллык планнар) нигезендә үткәрелә. Еллык планнар № 294-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда прокуратура органнары белән килештерелергә тиеш. Министр тарафыннан расланган еллык планнар Министрлыкның "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

Социаль хезмәтләр күрсәтүчене план буенча тикшерүне еллык планга кертү өчен нигез булып өч ел, социаль хезмәтләрне яшәп торуны тәэмин итеп күрсәткән очракта – ике ел узу тора:

социаль хезмәтләр күрсәтүчене дәүләт теркәвенә алган көннән;

социаль хезмәтләр күрсәтүчене план буенча соңгы тикшерү тәмамланган көннән;

социаль хезмәтләр күрсәтүче, шул өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен башкара башлау турында тапшырылган

хәбәрнамәгә туры китереп, социаль хезмәтләр күрсәтү буенча эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлаган көннән алып (әлеге хәбәрнамәне тапшыруны таләп итүче эшләр башкару яки хезмәтләр күрсәтү очрагында).

2.4.2. Социаль хезмәтләр күрсәтүчене планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып торалар:

1) мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында Министрлык тарафыннан элегрәк бирелгән күрсәтмәнең социаль хезмәтләр күрсәтүче тарафыннан үтәлү срогы чыгу;

2) түбәндәге фактлар турында Министрлыкка гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат керү:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерелү куркынычы туу, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерелү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) кулланучыларның хокуклары бозылу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта);

3) Министрның Россия Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте кушуы буенча һәм прокуратура органына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек кысасында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләпләре нигезендә чыгарылган боерыгы (әмере).

Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны ачыкларга мөмкинлек бирмәүче мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматлары булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора алмый.

Урынга барып, социаль хезмәтләр күрсәтүчене планнан тыш тикшерү, андый социаль хезмәтләр күрсәтүче эшчәнлек алып бара торган урындагы прокуратура органы белән килештергәннән соң, Министрлык тарафыннан бу Административ регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасындагы “а” һәм “б” пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча үткәрелергә мөмкин.

2.5. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) турыдан-туры башкаручы вазыйфаи затлар.

Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) турыдан-туры башкаручы вазыйфаи затлар булып, Бүлекнең министрның (министр урынбасарының) тикшерү уздыру турындагы боерыгында (әмерендә) күрсәтелгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тора.

2.6. № 294-ФЗ Федераль законны бозган өчен социаль хезмәтләр күрсәтүченең җаваплылыгы.

№ 294-ФЗ Федераль законның бозылуына юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулаучы, тикшерүләр үткәрелүдән качарга тырышучы һәм (яки) мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында Министрлыкның күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәүче социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законы нигезендә җавап тота.

2.7. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндәге

җаваплылыгы.

2.7.1. Министрлык, аның вазыйфаи затлары, тиндәшле рәвештә, функцияләрен, хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәгән, тикшерү үткәргәндә законсыз гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта, Россия Федерациясе законы нигезендә җавап тота.

2.7.2. Россия Федерациясе законын һәм Татарстан Республикасы законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында Министрлык, андый чаралар күрелгән көннән башлап ун көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган социаль хезмәтләр күрсәтүчегә язмача хәбәр итәргә тиеш.

### 3. Социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә куела торган мәҗбүри таләпләр

Социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә куела һәм үтәлеше Министрлык тарафыннан контрольдә тотыла торган мәҗбүри таләпләр исемлеге, аларны билгеләүче норматив хокукый актлар исемлеге, тикшерү үткәргәндә социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр күрсәтә торган документлар исемлеге 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица. Социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив хокукый акт | Тикшерү үткәрелгәндә, юридик затлар, шәхси эшкуарлар күрсәтә торган документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Контрольдә тотылучы объектлар: социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр барысы да (социаль хезмәтләрне социаль хезмәтләр күрсәтүнең стационар формасында күрсәтүче, социаль хезмәтләр күрсәтүнең ярым стационар формасында күрсәтүче, өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү формасында күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр) | | |
| 1.1. Гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә эшчәнлек алып бару, шул исәптән лицензия булу. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 1 пункты;<br>Социаль хезмәтләрне стационар формада күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.3.1 пунктчасы;<br>Социаль хезмәтләрне ярым стационар формада күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.3.1 пунктчасы. | Матди-техник базаның, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасында (алга таба – ИППСУ) билгеләнгән социаль хезмәтләрне күрсәтү өчен квалификацияле кадрларның булуын раслаучы документлар. |

| | | |
|---|---|---|
| 1.2. Социаль хезмәтләр алучыларга, ИППСУга һәм социаль хезмәтләр алучылар яки аларның законлы вәкилләре белән № 442 Федераль закон таләпләре нигезендә төзелгән килешүләр шартларына туры китереп, социаль хезмәтләр күрсәтү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 2 пункты, 16 статьясының 3 өлеше, 17 статьясы. | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә килешүләр; социаль хезмәтләр алучыларның ИИПСУ нигезендә формалаштырылган “личное дело”лары. |
| 1.3. Сроклы социаль хезмәтләр күрсәтү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 3 пункты, 21 статьясы. | Социаль хезмәтләр алучының гаризасы, Сроклы социаль хезмәтләр күрсәтү турында бу хезмәтләрне алучы һәм күрсәтүче, күрсәтелгән сроклы социаль хезмәтләрнең төрләре, сроклары, датасы хакындагы һәм аларны күрсәтү шартлары хакындагы мәгълүматларны үз эченә алучы акт. Сроклы социаль хезмәтләр күрсәтү турында акт. |
| 1.4. Социаль хезмәтләр алучыларга яки аларның законлы вәкилләренә түләүсез аңлаешлы формада аларның хокуклары һәм бурычлары турында, социаль хезмәтләр күрсәтүнең төрләре, сроклары һәм аларны күрсәтү шартлары турында, бу хезмәтләргә | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 4 пункты, 13 статьясы. | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең төрләре, сроклары һәм аларны күрсәтү шартлары турында, бу хезмәтләргә тарифлар турында һәм социаль хезмәтләр алучы өчен аларның бәясе турында яисә аларны түләүсез алу мөмкинлеге турында |

| | | |
|---|---|---|
| тарифлар турында һәм социаль хезмәтләр алучы өчен аларның бәясе турында яисә аларны түләүсез алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү. | | социаль хезмәтләр күрсәтүченең локаль актлары. |
| 1.5. Персональ мәгълүматлар хакындагы Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән персональ мәгълүматларны саклау турында таләпләргә туры китереп, социаль хезмәтләр алучылар турында мәгълүматны файдалануга таләпләрнең үтәлеше | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 5 пункты;<br>№ 152-ФЗ Федераль закон. | Социаль хезмәтләр алучыларның “личное дело”лары. |
| 1.6. Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр алучылар регистрын формалаштыру өчен, Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрнең Министрлыкка мәгълүматны үз вакытында тапшыруы. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 6 пункты, 26 статьясы;<br>Регистрны формалаштыру һәм алып баруның № 1012 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 5 пункты. | Социаль хезмәтләр алучыларның “личное дело”лары (социаль хезмәтләр алучылар регистрында социаль хезмәтләр алучылар турында мәгълүмат булу). |
| 1.7. Балигъ булмаган балаларның ата- | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы | ИППСУ (аларда чагылыш тапкан |

| | | |
|---|---|---|
| аналарын, опекуннарын, химаячеләрен, башка төрле законлы вәкилләрен дә кертеп, зарурлык булганда, гражданнарга медицина ягыннан, психологик, педагогик, юридик, социаль яки бүтән төрле социаль ярдәм күрсәтеп тору, шул исәптән андый ярдәмне күрсәтүче оешмаларны ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә җәлеп итү юлы белән. | беренче өлешенең 7 пункты, 22, 28 статьялары. | социаль ярдәм күрсәтеп тору чаралары белән). |
| 1.8. Зарурлык булганда, социаль хезмәтләр алучыларга Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре тарафыннан уздырылучы медицина-социаль экспертиза (алга таба – МСЭ) узуда булышуны тәэмин итү, шул исәптән инвалидлык төркемен билгеләү, үзгәртү, яисә инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасын төзү мсаксатларында гражданинны тикшерү, МСЭгә юллама алу максатыннан, медицина оешмаларында медицина тикшерүе узуда | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 8 пункты. | ИППСУ (аларда чагылыш тапкан МСЭ узуга шартлар тудыру чаралары белән). |

| | | |
|---|---|---|
| булышу, социаль хезмәтләр алучыны МСЭ үткәрү урынына транспортта алып барырга ярдәм итү, тернәкләндерүнең индивидуаль программасын гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү һ.б. | | |
| 1.9. Социаль хезмәтләрне куркынычсыз итеп күрсәтү. | Социаль хезмәтләрне стационар формада күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.3.2 – 1.3.4 пунктчалары;<br>Социаль хезмәтләрне ярым стационар формада күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.3.2 – 1.3.4 пунктчалары;<br>Социаль хезмәтләрне өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында күрсәтүнең № 1053 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 4.1 пункты. | Социаль хезмәтләр күрсәткәндә, куркынычсызлык, кулланылучы җайланмаларның, материалларның нормаларга туры килүе турындагы документлар; социаль хезмәтләр күрсәтүнең кулланмалары, кагыйдәләре, технологияләре һәм методикалары; җитештерүдәге контроль нәтиҗәләре, шул исәптән лаборатор тикшеренүләр һәм сынаулар уздыру ярдәмендә. |
| 1.10. Социаль хезмәтләрне сыйфатлы итеп күрсәтү өчен кирәкле персонал булу. | Социаль хезмәтләрне стационар формада күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.4.1 пунктчасы;<br>Социаль хезмәтләрне ярым стационар | Штат расписаниесе. |

| | | |
|---|---|---|
| | формада күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.4.1 пунктчасы;<br>Социаль хезмәтләрне өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында күрсәтүнең № 1053 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 6.3.1 пунктчасы. | |
| 1.11. Социаль хезмәтләр күрсәтүне туктатып торганда яки бөтенләй туктатканда нигезләрне саклау. | Социаль хезмәтләрне стационар формада күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.6 пункты;<br>Социаль хезмәтләрне ярым стационар формада күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.6 пункты;<br>Социаль хезмәтләрне өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында күрсәтүнең № 1053 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 4.6 пункты. | Социаль хезмәтләр алучыларның “личное дело”лары. |
| 1.12. Күрсәтелүче социаль хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән таләпләргә туры килү. | Социаль хезмәтләрне стационар формада күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.7 пункты;<br>Социаль хезмәтләрне ярым стационар формада күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары | Социаль хезмәтләр алучыларның “личное дело”лары. |

| | | |
|---|---|---|
| | белән расланган тәртибенең 1.7 пункты;<br>Социаль хезмәтләрне өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында күрсәтүнең № 1053 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 6.4 пункты. | |
| 1.13. Социаль хезмәтләр алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтле әйберләренең сакланышын тәэмин итү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 12 пункты;<br>Социаль хезмәтләрне стационар формада күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1 бүлеге;<br>Социаль хезмәтләрне ярым стационар формада күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1 бүлеге;<br>Социаль хезмәтләрне өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында күрсәтүнең № 1053 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 4.1 пункты. | Социаль хезмәтләр алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтле әйберләренең сакланышын тәэмин итү буенча локаль актлар. |
| 1.14. Социаль хезмәтләрнең билгеләнгән исемлеге һәм стандартларына туры китереп, социаль хезмәтләр күрсәтү буенча таләпләрне үтәү. | Социаль хезмәтләрне стационар формада күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1 нче кушымтасы;<br>Социаль хезмәтләрне ярым стационар | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә килешүләр; социаль хезмәтләр алучыларның “личное дело”лары. |

| | | |
|---|---|---|
| | формада күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1 нче кушымтасы;<br>Социаль хезмәтләрне өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында күрсәтүнең № 1053 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 1.3 пункты, кушымтасы. | |
| 1.15. Социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләүнең күләмен исәпләүнең дөреслеге өлешендәге контрольдән тыш, түләүле, өлешчә түләүле яки түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтү буенча таләпләрне үтәү. | Социаль хезмәтләрне стационар формада күрсәтүнең № 1100 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 2.2, 3.2, 4.2, 5.2, 6.2, 7.2 пунктчалары;<br>Социаль хезмәтләрне ярым стационар формада күрсәтүнең № 1101 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 2.2, 3.2, 4.2, 5.2 пунктчалары;<br>Социаль хезмәтләрне өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында күрсәтүнең № 1053 ТР МК карары белән расланган тәртибенең 3.1 – 3.5 пунктлары. | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә килешүләр. |
| 1.16. Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 9 пункты. | Социаль хезмәтләр күрсәтүченең локаль актлары. |

| | | |
|---|---|---|
| ярым стационар формасында хезмәт күрсәтүләр алганда, социаль хезмәтләр алучыларга элемтә, шул исәптән “Интернет” челтәре хезмәтләре һәм почта элемтәсе хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге бирү. | | |
| 1.17. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасында яшәүче хәләл җефетләргә аерым торак бүлмәсе бирү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 10 пункты. | Социаль хезмәтләр күрсәтүченең локаль актлары. |
| 1.18. Социаль хезмәтләр алучыларга көндез һәм кичке вакытта алар янына законлы вәкилләренең, адвокатларның, нотариусларның, иҗтимагый һәм (яки) башка оешмалар вәкилләренең, дин әһелләренең, шулай ук туганнарының һәм бүтән кешеләрнең каршылыксыз килеп йөрүе мөмкинлеген тәэмин итү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясы беренче өлешенең 11 пункты. | Социаль хезмәтләр күрсәтүченең локаль актлары.<br>Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре. |

## 4. Тикшерү үткәрелгәндә, социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тапшыра торган документлар

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларны ирешү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тапшыра торган документлар исемлеге, шулай ук андый документларның формаларын раслаучы норматив хокукый актлар 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица. Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларны ирешү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тапшыра торган документлар исемлеге

| Тикшерү үткәрү өчен тапшырылучы документ | Документның формасын билгеләүче норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1. Юридик затның уставы. | ГОСТ Р 53060-2008 “Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең документлары”. |
| 2. Җитәкче вазыйфасына билгеләү турында боерык, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүченең вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең вәкаләтләрен билгеләүче документлар. | Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 68 нче статьясы. |
| 3. Социаль хезмәтләр күрсәтүгә килешүләр | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының № 874н боерыгына 1 нче кушымта. |
| 4. Социаль хезмәтләр алучыларның “личное дело”лары. | |
| 5. Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен урнаштыру турында локаль акт. | Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 189 нчы статьясы. |

| | |
|---|---|
| 6. Штат расписаниесе. | ГОСТ Р 53060-2008 “Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең документлары; № Т-3 унификацияләнгән форма, Госкомстатның 2004 елның 5 гыйнварындагы “Хезмәтне һәм аңа түләүне исәпкә алу буенча беренчел исәп-хисап документларының унификацияләнгән формаларын раслау турында” № 1 карары белән расланган. |
| 7. Социаль хезмәтләр күрсәтүченең социаль хезмәтләрнең төрләре, сроклары, тәртибе турында һәм аларны күрсәтү шартлары турында, бу хезмәт күрсәтүләргә тарифлар турында һәм социаль хезмәтләр алучы өчен аларның бәсе турында яисә аларны түләүсез алу мөмкинлге турында локаль актлары. | |
| 8. Социаль хезмәтләр алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтле әйберләренең сакланышын тәэмин итү буенча локаль акт. | |

## 5. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

5.1 Дәүләт функциясен үтәгәндә башкарыла торган административ процедуралар исемлеге.

5.1.1. Региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) үткәргәндә юридик затны һәм (яки) шәхси эшкуарны планлы яки планнан тыш тикшерү тормышка

ашырыла.

Планлы тикшерү урынга барып тикшерү рәвешендә үткәрелә.

Планнан тыш тикшерү документларны тикшерү һәм (яки) урынга барып тикшерү рәвешендә үткәрелә.

5.1.2. Планлы тикшерү ярдәмендә тормышка ашырыла торган дәүләт функциясен үтәү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) тикшерү үткәрүләрне планлаштыру;

2) тикшерү үткәрүгә әзерләнү;

3) тикшерү үткәрү (планлы урынга барып);

4) тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

5) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү;

5.1.3. Планнан тыш тикшерү ярдәмендә тормышка ашырыла торган дәүләт функциясен үтәү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) тикшерү үткәрүгә әзерләнү;

2) тикшерү үткәрү (планнан тыш документларны тикшерү һәм (яки) планнан тыш урынга барып тикшерү);

3) тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

4) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү;

5.1.4. Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы бу Административ регламентка 1 нче кушымтада бирелә.

Дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган очракларда рөхсәт ителә.

5.2. “Тикшерүләр үткәрүне планлаштыру” административ процедурасы.

5.2.1. Административ процедураны башлау өчен нигез булып еллык планны әзерләү сроклары житү тора.

5.2.2. Еллык план Бүлек тарафыннан № 294-ФЗ Федераль законга туры китереп эшләнә. Еллык планны әзерләү тәртибе һәм сроклары, шул исәптән аны прокуратура органнарына җибәрү һәм прокуратура органнары белән килештерү, шулай ук еллык планның типовой формасы дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарының һәм муниципаль контроль органнарының РФ Хөкүмәтенең № 489

карары белән расланган оешмаларны планлы тикшерү үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләре белән билгеләнгән.

Еллык планга социаль хезмәтләр күрсәтүчене планлы тикшерүгә кертү өчен нигез булып бу административ регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.2.3. Бүлек начальнигы еллык планны әзерләү өчен җаваплы башкаручы (җаваплы башкаручылар) (алга таба – еллык планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы) билгели.

Үтәү срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдан килгән елның 1 августыннан да соңга калмыйча.

5.2.4. Еллык планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне тормышка ашыра:

- билгеләнгән форма буенча еллык план проектын төзи;

- аны Бүлек начальнигы, министр белән килештерә;

үтәү срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдан килгән елның 23 августыннан да соңга калмыйча;

- еллык план проектын кәгазьдә (электрон рәвештә күчермәсен кушып) заказлы почта элемтәсе аша тапшыру турында хәбәрнамә белән яки “Электрон имза турында” (алга таба – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза) 2011 ел, 6 апрель, № 63-ФЗ Федераль закон нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, карап тикшерү өчен, аларга карата планлы тикшерүләр үткәрү планлаштырылган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр урнашкан урындагы прокуратура органына җибәрә.

Үтәү срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдан килгән елның 1 сентябренә кадәр.

5.2.5. Еллык план проекты прокуратура органы тарафыннан карап тикшерелгәннән һәм тәкъдимнәр кертелгәннән соң, еллык планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы:

- еллык план проектына, прокуратура органыннан килгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, төзәтмәләр кертә;

- үзгәрешләр кертелгән еллык план проектын Бүлек начальнигы белән килештерә;

- еллык план проектын раслау өчен министрга җибәрә;

- еллык план министр тарафыннан расланганнан соң аны кәгазьдә (электрон рәвештә күчермәсен кушып) заказлы почта элемтәсе аша тапшыру турында хәбәрнамә белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә тиешле прокуратура органына җибәрә.

Үтәү срогы: расланган еллык планны прокуратурага җибәрү – планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдан килгән елның 1 ноябренә кадәр.

5.2.6. Еллык планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы расланган еллык планны министрлыкның рәсми сайтына урнаштыруны оештыра.

Үтәү срогы: еллык план расланган моменттан 5 эш көне эчендә.

5.2.7. Еллык планга үзгәрешләр кертү раслаучы документлар булганда (юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан дәүләт теркәве турында язма кертелү, юридик затны, шәхси эшкуарны ябу (реестрдан чыгару) турында өземтәләр) түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

- түбәндәгеләр белән бәйле рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтүче эшчәнлеген планлы тикшерү үткәрү мөмкинлеге булмау:

социаль хезмәтләр күрсәтүче – юридик затның бетерелүе яки үзгәртеп оештырылуы;

социаль хезмәтләр күрсәтүченең эшчәнлеген туктатуы;

- җиңеп чыга алмаслык көчтәге хәлләр башлану.

Еллык планга үзгәрешләр кертү министр боерыгы белән тормышка ашырыла. Кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүматлар алар кертелгән көннән 10 көнлек срок эчендә билгеләнгән тәртиптә тиешле прокуратура органына җибәрелә һәм министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

5.3. “Тикшерү үткәрүгә әзерләнү” административ процедурасы.

5.3.1. Административ процедураны башлауга нигез булып еллык планга туры китереп планлы тикшерү үткәрү срогы җитү яки планнан тыш тикшерү

үткәрү өчен бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күздә тотылган нигезләр булуы тора.

5.3.2. "Тикшерү үткәрүгә әзерләнү" административ процедурасы үз эченә түбәндәге гамәлләрне ала:

- тикшерү үткәрү турында карар кабул итү, җаваплы башкаручы билгеләү;

- тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы (әмере) әзерләү;

- социаль хезмәтләр күрсәтүчегә тикшерү үткәрү турында хәбәр итү.

5.3.3. Тикшерү үткәрү турында карар кабул итү, җаваплы башкаручы билгеләү.

Еллык план яки планнан тыш тикшерү үткәрүгә министр, министр урынбасары кушуы нигезендә Бүлек начальнигы, тиңдәшле рәвештә, планлы яки планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат (вазыйфаи затлар) (алга таба – җаваплы башкаручы) билгели.

Планнан тыш тикшерү үткәрү формасы (документларны тикшерү яки урынга барып тикшерү) тикшерү үткәрү урындагы боерыкта (әмердә) күрсәтелә.

Үтәү срогы:

- планлы тикшерү датасына кадәр ундүрт эш көненнән дә ким булмаган көн кала яки тикшерүләрнең еллык планын төзегәннән соң ук;

- бу Административ регламентның 2.4.2 пунктының 2 һәм 3 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү үткәрү турында министр, министр урынбасары йөкләмәсен кабул иткән көнне;

- ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәнең үтәлеше турында социаль хезмәтләр күрсәтүче тарафыннан мәгълүмат (хәбәрнамә) бирелгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

5.3.4. Тикшерү үткәрү турында боерык (әмер) әзерләү.

5.3.4.1. Тикшерү үткәрү турындагы карар бу Административ регламентка № 2 кушымта нигезендә типовой формага тиңдәшле рәвештә тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы (әмере) белән рәсмиләштерелә

Җаваплы башкаручы:

- тикшерү үткәрү турында боерык (әмер) әзерли;

- тикшерү үткәрү турында боерыкны (әмерне) Бүлек начальнигы белән килештерә;

- тикшерү үткәрү турында боерыкны (әмерне) имза кую өчен министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрү турында карар кабул иткән һәм җаваплы башкаручы билгеләнгән көннән соң килүче бер эш көне эчендә.

5.3.4.2. Тикшерү үткәрү турындагы боерыкта (әмердә) күрсәтелә:

Министрлыкның атамасы;

тикшерү үткәрергә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрүгә җәлеп ителүче экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең вазыйфалары, фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

тикшерү үткәрелә торган юридик затның атамасы яки шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерым структур бүлекчәләренең) урнашу урыннары яки шәхси эшкуарларның чынлыкта эшчәнлекләрен тормышка ашыру урыннары;

тикшерүнең максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү сроклары;

тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре, шул исәптән тикшерелергә тиешле мәҗбүри таләпләр;

тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен күзәтчелек буенча кирәкле чаралар исемлеге һәм үткәрү сроклары;

дәүләт функциясен үтәү буенча Административ регламентлар исемлеге;

тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан бирелергә тиешле документлар исемлеге;

тикшерү үткәрүнең башлану һәм тәмамлану даталары.

5.3.4.3. Әгәр планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү өчен нигез булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктның 2 пунтчасының “а” һәм “б” пунктчаларында күрсәтелгән нигез булса, җаваплы башкаручы планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрүне килештерү турында социаль хезмәтләр күрсәтүче

эшчәнлеген тормышка ашыру урыны буенча прокуратура органына гариза әзерли, аңа министрдан (министр урынбасарыннан) имза куйдыра.

Үтәү срогы: планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү турында боерык (әмер) имзаланган көнне.

Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планнан тыш урынга барып тикшерүләрне үткәрүне прокуратура органнарында килештерү тәртибе Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын саклау турында"гы 26.12.2008, № 294-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру хакында" 27.03.2009, № 93 боерыгы белән расланган.

Юридик затны һәм шәхси эшкуарны планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрүне дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарының прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның типовой формасы Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган.

5.3.5. Социаль хезмәтләр күрсәтүчегә тикшерү үткәрү турында хәбәр итү.

5.3.5.1. Җаваплы башкаручы социаль хезмәтләр күрсәтүчегә планлы тикшерү үткәрү турында ул башлануга өч эш көненнән дә соңга калмыйча тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) күчермәсен, тапшыру турында хәбәрнамә белән, заказлы хат итеп почта аша җибәрү ярдәмендә яки башка кулай алым белән (факсимиль элемтә ярдәмендә, алу турында тамга белән кулга тапшыру) хәбәр итә.

5.3.5.2. Министрлыкка гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләре, гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм-мәгълүмат чараларыннан гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү (зыян китерелү куркынычы туу), хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт куркынычсызлыгына зыян китерелү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү (куркынычы янау), шулай ук кулланучыларның хокуклары бозылу (хокуклары

бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта) фактлары турында мәгълүмат керү нигезе буенча үткәрелгән планнан тыш урынга барып тикшерүдән тыш, җаваплы башкаручы социаль хезмәтләр күрсәтүчегә планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү турында тикшерү башлануга егерме дүрт сәгатьтән дә ким булмаган вакыт кала, мөмкин булган теләсә нинди алым белән хәбәр итә.

5.3.6. "Тикшерү үткәрүгә әзерләнү" административ процедурасының нәтиҗәсе:

1) тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) кул куйган, тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар күрсәтелгән боерык (әмер);

2) социаль хезмәтләр күрсәтүчегә тикшерү үткәрү турында хәбәр итү.

5.4. "Тикшерү үткәрү" административ процедурасы.

5.4.1. Административ процедураны башлауга нигез булып министрның (министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турындагы боерыгы (әмере) тора.

Тикшерү бары тик тикшерү үткәрү турындагы боерыкта (әмердә) күрсәтелгән вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә ала.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү үткәрүче җаваплы башкаручы тарафыннан бу Административ регламентның 5.5 бүлекчәсенә туры китереп акт төзелә.

Тикшерү үткәрү срогы бу Административ регламентның 2.3 пунктындагы таләпләргә туры килергә тиеш.

Тикшерү үткәрү өчен җаваплы булып министр (министр урынбасары) боерыгы (әмере) белән конкрет тикшерү үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар тора.

5.4.2. Планлы тикшерү.

5.4.2.1. Социаль хезмәтләр күрсәтүчене планлы тикшерү бу административ регламентның 5.2 бүлекчәсенә туры китереп эшләнгән һәм расланган тикшерүләрнең еллык планы нигезендә үткәрелә.

5.4.2.2. Планлы тикшерүнең предметы булып социаль хезмәтләр күрсәтүче тарафыннан эшчәнлекне тормышка ашыру барышында куелган мәҗбүри таләпләр җыелмасының үтәлүе, шулай ук эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен

башлау турындагы хәбәрнамәдәге мәгълүматларның мәҗбүри таләпләргә туры килүе тора.

5.4.3. Планнан тыш тикшерү.

5.4.3.1. Планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктчасында күрсәтелгән очраклар тора.

Социаль хезмәт күрсәтүчене планнан тыш урынга барып тикшерү бу Административ регламентның 2.4.2 пунктның 2 пунтчасының "а" һәм "б" пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча министрлык тарафыннан шундый социаль хезмәтләр күрсәтүче эшчәнлеген тормышка ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелергә мөмкин.

5.4.3.2. Планнан тыш тикшерүнең предметы булып социаль хезмәтләр күрсәтүче тарафыннан эшчәнлеген тормышка ашыру барышында мәҗбүри таләпләрнең, министрлык күрсәтмәләренең үтәлүе, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян салуны булдырмау, дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча, шундый зыянның нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар үткәрелүе тора.

Әгәр планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып социаль хезмәтләр күрсәтүче тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрнең бозылуын бетерү турындагы күрсәтмәне үтәү срогы чыгу булса, мондый тикшерүнең предметы булып бары тик министрлык биргән күрсәтмәләрне үтәү генә тора ала.

5.4.4. Документларны тикшерү.

5.4.4.1. Документларны тикшерү министрлык урнашкан урында үткәрелә.

5.4.4.2. Документларны тикшерүнең предметы булып социаль хезмәтләр күрсәтүченең документларында булган аның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгеләүче мәгълүматлар, аның эшчәнлеген тормышка ашырганда файдаланыла торган һәм мәҗбүри таләпләрне үтәү, министрлыкның күрсәтмәләрен һәм карарларын үтәү белән бәйле документлар тора.

5.4.4.3. Документларны тикшерү үткәрү барышында җаваплы башкаручы

тарафыннан беренче чиратта социаль хезмәтләр күрсәтүченең министрлык карамагында булган документлары, моннан алдагы тикшерү актлары, административ хокук бозулар турында каралган эш материаллары һәм социаль хезмәтләр күрсәтүчегә карата үткәрелгән контроль нәтиҗәләре турындагы башка документлар карап тикшерелә

5.4.4.4. Әгәр министрлык карамагындагы документларда булган мәгълүматларның дөреслеге нигезле шикләнүләр тудырса яки бу мәгълүматлар социаль хезмәтләр күрсәтүченең мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, әгәр хаталар һәм (яки) каршылыклар, министрлыкка җибәрелгән һәм булган документлардагы мәгълүматларның туры килмәве ачыкланса, җаваплы башкаручы документларны тикшерү үткәрү барышында карап тикшерү өчен кирәкле башка документлар җибәрү таләбе белән нигезле рәсми мөрәҗәгать әзерли һәм аны заказлы почта элемтәсе аша, тапшыру турында хәбәрнамә биреп, яки башка кулай алым белән социаль хезмәт күрсәтүче адресына җибәрә. Рәсми мөрәҗәгатькә кушымта итеп тикшерү үткәрү турында мөһер белән расланган боерык (әмер) күчермәсе җибәрелә.

Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә министрлык түләүсез нигездә башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яки карамагында бу документлар һәм (яки) мәгълүмат булган дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән срокларда һәм тәртиптә сората һәм ала.

5.4.4.5. Социаль хезмәтләр күрсәтүче рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны нигезле рәсми мөрәҗәгать алган көннән соң ун эш көне эчендә министрлыкка җибәрергә тиеш. Рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документлар мөһер белән (әгәр ул булса) һәм ярашлы рәвештә җитәкче, социаль хезмәтләр күрсәтүченең башка вазыйфаи заты имзасы белән расланган күчермәләр рәвешендә җибәрелә. Социаль хезмәтләр күрсәтүче рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә

көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документлар рәвешендә җибәрә ала.

5.4.4.6. Җаваплы башкаручы җитәкче яки социаль хезмәтләр күрсәтүченең башка вазыйфаи заты тапшырган алдан бирелгән документларның дөреслеген раслаучы аңлатмаларны һәм документларны карап тикшерергә тиеш. Әгәр тапшырылган аңлатмалар һәм документларны карап тикшергәннән соң яки аңлатмалар булмаганда мәҗбүри таләпләрнең бозылу билгеләре ачыкланса, җаваплы башкаручы урынга барып тикшерү үткәрү турында боерык (әмер) проекты әзерләү юлы белән урынга барып тикшерү үткәрүне башларга хаклы. Урынга барып тикшерү үткәрү турында карарны министр, министр урынбасары кабул итә.

5.4.4.7. Документларны тикшерү үткәргәндә министрлыкның социаль хезмәтләр күрсәтүчедән документларны тикшерү предметына кагылмаган мәгълүматлар һәм документларны таләп итәргә хакы юк, шулай ук министрлык тарафыннан дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) башка органнарыннан алырга мөмкин булган мәгълүматлар һәм документларны да.

5.4.4.8. Социаль хезмәтләр күрсәтүче тарафыннан аларны тапшыру законда күздә тотылган һәм региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашыру өчен кирәкле мәгълүматлар (информация) бирелмәгәндә яки вакытында бирелмәгәндә, яисә министрлыкка бирелгән андый мәгълүматлар (информация) тулы күләмдә булмаса яки бозып күрсәтелсә, РФ АХбКта каралган тәртиптә РФ АХбКның 19.7 матдәсе буенча административ хокук бозу турында эш кузгатыла.

5.4.5. Урынга барып тикшерү.

5.4.5.1. Урынга барып тикшерү (планлысы да, планнан тышы да) юридик затның урнашкан урынында, шәхси эшкуарның эшчәнлеген тормышка ашырган урында һәм (яки) аларның чынлыкта эшчәнлекләрен тормышка ашырган урында (тикшерү үткәрү урыны) үткәрелә.

5.4.5.2. Урынга барып тикшерүнең предметы булып социаль хезмәтләр күрсәтүченең документларында булган мәгълүматлар, шулай ук аларның хезмәткәрләренең туры килүе, күрсәтелгән затлар тарафыннан эшчәнлекләрен

тормышка ашырганда файдаланыла торган территорияләрнең, биналарның, корылмаларның, каралты, помещениеләрнең, җиһазларның, шуңа охшаш объектларның халәте, башкарыла торган эш, күрсәтелә торган хезмәтләр һәм мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча алар тарафыннан күрелә торган чаралар тора.

5.4.5.3. Урынга барып тикшерү әгәр документларны тикшергәндә түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) социаль хезмәт күрсәтүченең министрлык карамагындагы документларында булган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшереп белү;

2) социаль хезмәтләр күрсәтүче эшчәнлегенең контроль буенча тиешле чара үткәрмичә мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү.

5.4.5.4. Җаваплы башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

- тикшерү үткәреләсе урынга тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгында (әмерендә) билгеләнгән срокта килә;

- хезмәт таныклыгын күрсәтә һәм җитәкчегә яки башка вазыйфаи затка, социаль хезмәт күрсәтүче вәкаләт биргән вәкилгә кул куйдырып, мөһер белән расланган тикшерү үткәрү турындагы боерык (әмер) күчермәсен тапшыра;

үтәү срогы: тикшерү үткәрү урынына килеп җитү белән;

- җитәкчегә яки башка вазыйфаи затка, социаль хезмәт күрсәтүче вәкаләт биргән вәкилгә урынга барып тикшерү билгеләнү, урынга барып тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре, шулай ук урынга барып тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контроль буенча чараларның төре һәм күләме, экспертлар составы, урынга барып тикшерүгә җәлеп ителгән эксперт оешмалары вәкилләре, аны үткәрүнең сроклары һәм шартлары турында хәбәр итә.

үтәү срогы: тикшерү үткәрү урынына килеп җитү белән;

- документлардагы тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле мәгълүматларны өйрәнә;

- социаль хезмәтләр күрсәтүче тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерә (бу Административ регламентның 3 нче бүлегенә туры китереп);

- кирәк булганда урынга барып тикшерү предметына кагылышлы сораулар

буенча документлар һәм материаллар, шулай ук җитәкчедән яки башка вазыйфаи затлардан, социаль хезмәт күрсәтүче вәкаләт биргән вәкилдән язмача аңлатмалар сората, җитәкче һәм/яки хезмәткәрләр белән тикшерү предметына кагылышлы сораулар буенча әңгәмәләр үткәрә;

- тикшерү предметына кагылышлы сораулар буенча тапшырылган документларны, материалларны һәм аңлатмаларны анализлый һәм мәҗбүри таләпләрнең бозылуы булу (булмау) турында карар кабул итә;

- бозылу фактлары ачыкланганда:

билгеләнгән тәртиптә бозылу фактлары булуны раслучы документларның күчермәләрен әзерли һәм раслый (алга таба – раслаучы документлар);

мәҗбүри таләпләрнең бозылу фактлары турында мәгълүматларны, раслаучы документларның күчермәләрен теркәп, тикшерү актына кертә.

5.4.5.5. Җаваплы башкаручы үз вәкаләтләрен раслау максатларында җитәкче яки башка вазыйфаи зат, социаль хезмәт күрсәтүче вәкаләт биргән вәкил соравы буенча министрлык турында, шулай ук экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә, шулай ук бу Административ регламент белән һәм социаль хезмәтләр күрсәтүче эшчәнлеген тормышка ашырганда файдалана торган объектларда контроль буенча чаралар үткәрү тәртибе белән таныштырырга бурычлы.

5.4.5.6. “Тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәләре булып тора:

- тикшерү үткәрү турындагы боерык (әмер) нигезендә контроль буенча үткәрелгән чаралар;

- мәҗбүри таләпләрне бозулар булу яки булмауны ачыклау.

5.5. “Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү” административ процедурасы.

5.5.1. Административ процедураны үткәрүне башлауга нигез булып тикшерү үткәрү тәгәлләнү тора.

5.5.2. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, тикшерү үткәргән җаваплы башкаручы:

- ике нөсхәдә тикшерү акты әзерли, аңа беркетмәләр яки үткәрелгән тикшеренүләр, сынау һәм экспертизалар нәтиҗәләрен, мәҗбүри таләпләрнең

бозылуы өчен җаваплылык төшкән социаль хезмәтләр күрсәтүче хезмәткәрләренең аңлатмаларын, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар яки аларның күчермәләрен терки;

үтәү срогы: тикшерү тәмамланганнан соң ук;

- 2 нөсхәдә тикшерү актын имзалый;

үтәү срогы: акт төзелгәннән соң ук;

- тикшерү актының бер данәсен кушымталарның күчермәләре белән тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында расписка белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки социаль хезмәтләр күрсәтүче вәкаләт биргән вәкилгә тапшыра;

үтәү срогы: актка кул куйганнан соң ук;

- җитәкче, башка вазыйфаи зат яки социаль хезмәт күрсәтүче вәкаләт биргән вәкил булмаган очракта, шулай ук тикшерелгән зат тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, тикшерү актын заказлы хат итеп почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: актка кул куйганнан соң ук;

- тикшерү актының икенче нөсхәсенә тиешле язма кертә, аңа заказлы хатны тапшыру турында хәбәрнамәне беркетә;

үтәү срогы: тикшерү актын заказлы почта аша җибәргәннән соң ук;

- тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән, яки ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актына социаль хезмәтләр күрсәтүченең язмача ризасызлыкларын (булса) терки;

үтәү срогы: социаль хезмәтләр күрсәтүче алганнан соң ук.

5.5.3. Тикшерелгән затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә үзара хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булганда тикшерү акты бу актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка

яки социаль хезмәтләрне күрсәтүче вәкаләт биргән вәкилгә җибәрелергә мөмкин. Шуның белән бу актны төзегән затның көчәйтелгән электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә тикшерелгән затның күрсәтелгән документны алуын раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрелгән акт тикшерелгән зат тарафыннан алынган дип санала. Актны алу турында хәбәрнамә тикшерү актының Министрлыктагы делода саклана торган нөсхәсенә беркетелә.

5.5.4. Әгәр тикшерү акты төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча йомгак алырга кирәк булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар тәгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган срокта төзелә һәм җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки социаль хезмәтләр күрсәтүче вәкаләт биргән вәкилгә расписка белән тапшырыла яисә заказлы хат итеп почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән һәм (яки) бу актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә җибәрелә (тикшерелгән затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә үзара хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган шартларда, бу документның алынуын раслауны тәэмин итүче ысул белән). Шуның белән тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яки) күрсәтелгән документны алуны башкача раслау тикшерү актының Министрлыктагы делода саклана торган нөсхәсенә беркетелә.

5.5.5. Тикшерү актында күрсәтелә:

1) тикшерү актының төзелү датасы, вакыты, урыны;

2) Министрлыкның атамасы;

3) тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгының (әмеренең) датасы һәм номеры;

4) тикшерү үткәрүче вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазифалары;

5) тикшерелә торган юридик затның атамасы яки шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, шулай ук тикшерү үткәргәндә катнашкан җитәкченең, башка вазыйфаи затның яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм

вазыйфасы;

6) тикшерү үткәрүнең датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм үткәрү урыны;

7) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән ачыкланган мәҗбүри таләпләр бозылу турында, аларның характеры һәм күрсәтелгән бозуларга юл куйган затлар турында мәгълүматлар;

8) тикшерү үткәрүдә катнашкан җитәкченең, башка вазыйфаи затның яки социаль хезмәтләр күрсәтүченең вәкаләтле вәкиленең тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турында, аларның имзалары булу яки кул куюдан баш тарту турында мәгълүматлар, шулай ук тикшерүләрне исәпкә алу журналына үткәрелгән тикшерү турында язма кертү турында яисә социаль хезмәтләр күрсәтүчедә әлеге журнал булмау белән бәйле рәвештә мондый язманы кертү мөмкин булмау турында мәгълүматлар;

9) тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның имзалары.

5.5.6. Әгәр планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү өчен аны үткәрү прокуратура органы белән килештерүне таләп иткән булса, җаваплы башкаручы тикшерү актының күчермәсен тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул ителгән прокуратура органына җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү акты төзелгән көннән биш эш көне эчендә.

5.5.7. Җаваплы башкаручы урынга барып үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына, Министрлыкның атамасы, тикшерү үткәрүнең башланган һәм тәмамланган даталары, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезләр, тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында мәгълүматлар булган, тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары, аның яки аларның имзалары күрсәтелгән язма кертә.

Үтәү срогы: турыдан-туры урынга барып тикшерү тәмамланганнан соң.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, җаваплы башкаручы тикшерү актында бу хакта язма ясый.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы тегелгән, номер сугылган һәм социаль хезмәтләр күрсәтүче мөһере белән (мөһере булса) расланган булырга тиеш.

5.5.8. Тикшерү үткәрелгән социаль хезмәтләр күрсәтүче тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән, яки ачыкланган бозылуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта тикшерү актын алган датадан унбиш көн эчендә Министрлыкка язма рәвештә тикшерү актына карата һәм (яки) ачыкланган бозылуларны бетерү турындагы күрсәтмәгә тулысынча, яки аның аерым нигезләмәләренә карата ризасызлыгын җиткерергә хаклы. Шуның белән бергә социаль хезмәтләр күрсәтүче Министрлыкка мондый ризасызлыкларның нигезле булуын раслаучы документлар, яки аларның расланган күчермәләрен тапшырырга хаклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документлар рәвешендә (электрон документлар пакеты) җибәрелергә мөмкин.

5.5.9. Тикшерү тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуын, бирелгән күрсәтмәләрдәге мәгълүматларны, административ хокук бозулар турында рәсмиләштерелгән беркетмәләрне аерым күрсәтеп, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның рәсми сайтына мәгълүмат урнаштыруны оештыра.

Үтәү срогы: тикшерү тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә.

5.5.10. “Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәләре булып тора:

- кушымталары белән тикшерү акты;

- үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булганда) язма;

- тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештергән очракта – прокуратура органына җибәрелгән тикшерү акты күчермәсе.

5.6. “Мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуларын бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасы.

5.6.1. Административ процедураны башлауга нигез булып мәҗбүри таләпләрнең ачылган бозылулары тора.

5.6.2. Күрсәтмә тапшыру.

5.6.2.1. Тикшерү үткәргәндә мәҗбүри таләпләрнең бозылу очрагы ачыкланганда, җаваплы башкаручы:

- аларны бетерү срокларын күрсәтеп, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт куркынычсызлыгына, физик һәм юридик затларның милкенә, дәүләт милкенә һәм муниципаль милеккә зыян китерелүне булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуны кисәтү, шулай ук федераль законнар белән күздә тотылган башка чаралар үткәрү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә) әзерли һәм тапшыра;

үтәү срогы: тикшерү тәмамланганнан соң ук, тикшерү акты белән бергә;

- ачыкланган бозуларны бетерүгә, аларны кисәтүгә, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә) зыян китерелү ихтималын булдырмауга, дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итүгә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуны кисәтүгә контроль буенча чаралар күрә;

үтәү срогы: күрсәтелгән очракларны кисәтү, булдырмау – бозуларны ачыклаганнан соң ук; бетерүгә контроль – бетерү периоды дәвамында.

5.6.2.2. Күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып тора, тикшерү акты белән бергә рәсмиләштерелә һәм социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, бу Административ регламентның 5.5.4. пунктына туры китереп, тикшерү акты белән бергә тапшырыла (җибәрелә).

5.6.2.3. Күрсәтмәне үтәү срогы беткәнгә кадәр социаль хезмәтләр күрсәтүче ачыкланган мәҗбүри таләп бозылуын бетерү һәм, раслаучы документларны кушып, күрсәтмәнең үтәлүе турында Министрлыкка мәгълүмат (хәбәрнамә) (алга таба – күрсәтмәнең үтәлүе турында мәгълүмат) җибәрергә тиеш.

5.6.2.4. Социаль хезмәтләр күрсәтүчедән күрсәтмәнең үтәлүе турында мәгълүматны алганнан соң, җаваплы башкаручы:

- күрсәтмәнең үтәлүе турында алынган мәгълүмат һәм кушымта итеп җибәрелгән документлар белән таныша;

үтәү срогы: күрсәтмәнең үтәлүе турында мәгълүмат алынган көннән алып биш эш көненнән артык түгел;

- күрсәтмәнең үтәлүе турында мәгълүматта бирелгән мәгълүматларны бәяләү һәм бирелгән күрсәтмәнең үтәлү (үтәлмәү) фактын ачыклау максатыннан, бу Административ регламентның 5.4.3 – 5.4.5 пунктларына туры китереп, күрсәтмәнең үтәлешен планнан тыш тикшерә;

үтәү срогы: бу Административ регламентның 2.3.1 пунктына туры китереп;

- бу Административ регламентның 5.5 бүлекчәсенә туры китереп, ике нөсхәдә тикшерү актын төзи;

үтәү срогы: тикшерү тәмамланганнан соң ук;

5.6.3. Административ хокук бозу турында беркетмә төзү.

5.6.3.1. Бу Административ регламентның 5.6.2.4 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш тикшерү барышында РФ АХБКның 19.5 статьясындагы 1 өлеш белән күздә тотылган хокук бозу – күрсәтмәне үтәмәү (шул исәптән әгәр күрсәтмәнең үтәлүе турында мәгълүмат күрсәтмәне үтәү срогы беткәнгә кадәр тапшырылмаса яисә күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлүен расламаса), яисә тикшерү барышында РФ АХБКның 19.6, 19.7 статьялары белән күздә тотылган хокук бозулар ачыкланган очракта, административ хокук бозу турындагы эшләр буенча беркетмә төзергә вәкаләтле вазыйфаи зат:

- административ хокук бозу турында эш кузгата – РФ АХБКның, тиңдәшле рәвештә, 19.5 статьясындагы 1 өлеш белән, 19.6 статьясы яки 19.7 статьясы белән күздә тотылган административ хокук бозу турында РФ АХБК белән күздә тотылган тәртип нигезендә беркетмә төзи;

үтәү срогы: хокук бозу булганлыгы ачыкланганнан соң кичекмәстән; тикшерү тәмамланганнан соң ук; күрсәтмәнең үтәлүе турында мәгълүмат тапшырылмаган очракта – күрсәтмәне үтәү срогы беткәннән соң килүче эш көне эчендә;

- аларга карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган физик

затка яки юридик затның законлы вәкиленә административ хокук бозу турында беркетмә белән танышырга мөмкинлек бирә (әлеге затлар беркетмәнең эчтәлеге буенча, беркетмәгә кушып куела торган аңлатмалар һәм искәртмәләр тапшырырга хокуклы);

- аңа карата беркетмә төзелгән затка административ хокук бозу турында беркетмәнең күчермәсен җибәрүне (кулына тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып, яки электрон почта аша) тәэмин итә;

үтәү срогы: беркетмә төзелгән көннән алып өч календарь көне эчендә;

- административ хокук бозу турында беркетмәне, кулына тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша, административ хокук бозу турында эшне карап тикшерү өчен гомуми юрисдикция судына җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: беркетмә төзелгән моменттан алып өч тәүлек эчендә;

- административ хокук бозу турында беркетмәнең эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртмәләрне, алар үзенә карата беркетмә төзелгән заттан кергән очракта, административ хокук бозу турындагы эшне тикшерә торган гомуми юрисдикция судына билгеләнгән тәртиптә җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: андый аңлатмалар яки искәртмәләрне алганнан соң ук;

- административ хокук бозу турында беркетмәнең күчермәсен тикшерү материалларына кушып куя;

үтәү срогы: административ хокук бозу турында беркетмә (беркетмәнең эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртмәләр) гомуми юрисдикция судына җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә.

5.6.4. “Мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуларын бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып тора:

- мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында күрсәтмә;

- административ хокук бозу турында суд органына җибәрелгән беркетмә.

## 6. Дәүләт функциясен үтәүне контрольдә тотуның тәртибе һәм формалары.

6.1. Министрлык вазыйфаи затларның үз хезмәт бурычларын үтәвен контрольдә тота, вазыйфаи затларның тикшерүләр үткәрү барышында үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәү очракларының исәбен алып бара, эш урынында тиешле тикшерүләр үткәрә һәм Россия Федерациясе законына туры китереп, андый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Дәүләт функциясенең үтәлеше министр тарафыннан контрольдә тотыла.

6.3. Министрлыкның вазыйфаи затларының бу Административ регламент нигезендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкару буенча гамәлләр эзлеклелеген үтәвенә, аларның карарлар кабул итүенә агымдагы контрольлек министр урынбасары, Бүлек начальнигы һәм Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан башкарыла.

6.4. Министрлыкның дәүләт функциясен үтәүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле хезмәткәрләре исемлеге, әлеге контрольне гамәлгә ашыруның тәртибе һәм ешлыгы Министрлык актлары белән гамәлгә кертелә. Министрлык хезмәткәрләренең агымдагы контрольне башкару вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазыйфаларына кагылышлы инструкцияләрдә билгеләнә.

6.5. Агымдагы контроль бу Административ регламентның нигезләмәләре һәм дәүләт функциясен үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче бүтән норматив хокукый актлар үтәлүне тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла. Тикшерүләр үткәрүнең тулылыгына һәм сыйфатына агымдагы контроль даими рәвештә алып барыла һәм гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылуны тикшерүне, ачыклауны һәм билгеләүне, андый закон бозуларны бетерү турында карарлар кабул итүне үз эченә ала.

6.6. Дәүләт функциясен үтәүгә контроль план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне үз эченә ала.

Дәүләт функциясен үтәүнең тулылыгын һәм сыйфатын план буенча тикшерүләр Министрлыкның агымдагы елга еллык эш планы нигезендә үткәрелә.

Планнан тыш тикшерүләр элегрәк ачыкланган закон бозуларның бетерелүен тикшерүгә бәйле рәвештә, шулай ук үз вазыйфаи бурычларын үтәгәндә

Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр нигезендә үткәрелә.

6.7. Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт функциясен, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, Россия Федерациясе законы нигезендә тикшерү үткәргәндә законсыз гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) өчен җавап тота.

Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышында алар тарафыннан кабул ителә (кылына) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен дисциплинар җаваплылыгы чикләре аларның вазыйфаларына кагылышлы регламентлар белән билгеләп куела.

Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында, андый чаралар күрелгән көннән башлап ун көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган социаль хезмәтләр күрсәтүчегә Министрлык язмача хәбәр итәргә тиеш.

6.8. Дәүләт функциясен үтәүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контроль берләшмәләр һәм оешмаларның уставларына туры китереп башкарыла. Билгеләп куелган вәкаләте чикләрендә Министрлык гражданнарга, иҗтимагый һәм бүтән төрле оешмаларга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтә. Дәүләт функциясен үтәү буенча җәмәгатьчелек контроленең Министрлыкка тапшырылган нәтиҗәләре Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә һичшиксез карап тикшерелергә тиеш.

## 7. Дәүләт функциясен үтәүче Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

7.1. Социаль хезмәтләр күрсәтүченең җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, мәнфәгатьле башка затлар (алга таба – гариза бирүче) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндәге, мәҗбүри таләпләр бозылуга китергән карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән

тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Гариза бирүче язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә, шикаятен, тиңдәшле рәвештә, почта аша яки Министрлыкның "Интернет" челтәрендәге сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru) файдаланып җибәрергә, шулай ук шикаятен Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирергә хокуклы.

7.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышында кабул иткән яки башкарган карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмаулары) тора.

7.3. Шикаятьне карап тикшерүне туктатып тору яки аны карап тикшерүдән баш тарту өчен нигезләр күздә тотылмаган. Министрлыкның яки вәкаләтләренә тәңгәл рәвештә вазыйфаи затка кергән шикаятьнең карап тикшерелүе мәҗбүри.

7.4. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми яисә анда куелган сорауларга тәфсилле җавап бирелми:

- әгәр шикаятьтә шикаятьне җибәргән гариза бирүченең фамилиясе (юридик затның атамасы) яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон адрес) күрсәтелмәгән булса;

- әгәр шикаятькә сүгенү яисә мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар кергән булса (Министрлыкның вазыйфаи заты шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә үз хокукларыннан явызларча файдаланырга ярамау турында хәбәр итәргә хокуклы);

- әгәр язмача шикаятьнең тексты укырлык булмаса (аның фамилиясе һәм почта адресы (электрон адресы) укырлык булган очракта, шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә, шикаять теркәлгән көннән башлап 7 көн эчендә бу хакта хәбәр ителә);

- әгәр гариза бирүченең шикаятендә элегрәк җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә аңа берничә тапкыр язмача тәфсилле җаваплар бирелгән сорау булса, һәм бу очракта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә (министр, вазыйфаи зат яисә шуңа вәкаләтле зат чираттагы шикаятьнең нигезсезлеге

турында һәм әлеге мәсьәлә буенча гариза бирүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы (әлеге шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр Министрлыкка яки шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән очракта); шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә язышуны туктату турындагы әлеге карар хакында хәбәр ителә).

Әгәр шикаятьтә әзерләнүче, кылынучы яки кылынган законга каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар булса, шикаять, вәкаләтенә туры китереп, дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына карата белдерелүче шикаять, теркәлгән көненнән башлап җиде көн эчендә, әлеге суд карарына карата шикаять белдерүнең тәртибе аңлатылып, гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Шикаятьтә куелган сорауларга тәфсилле җавап бирү мөмкин булмауның сәбәпләре тора-бара бетерелгән очракта, гариза бирүче шикаятен Министрлыкка яки аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.

7.5. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып, гариза бирүчедән (гариза бирүченең вәкаләтле вәкиленнән) шәхсән, яки почта аша хат рәвешендә, яки E-mail: mtsz@tatar.ru электрон адресына җибәрелгән яки Министрлыкның рәсми сайты (http://mtsz.tatarstan.ru) аша электрон документ рәвешендә Министрлыкка мөрәҗәгать (шикаять) керү тора.

7.6. Гариза бирүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алуга хокуклы. Андый төрдәге мәгълүматны һәм документларны алу өчен, гариза бирүчеләр Министрлык адресына язмача яки электрон рәвештә бу хакта рәсми мөрәҗәгать җибәрергә тиешләр.

7.7. Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять министрга җибәрелергә мөмкин. Министрлыкның һәм министрның гамәлләренә (гамәл кылмауларына), карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.8. Шикаятьләр Министрлык тарафыннан алар теркәлгән көннән башлап 30

календарь көне эчендә карап тикшерелә.

7.9. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүнең нәтиҗәләре булып тора:

- төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашыру барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (башкарылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, ә тәгаен:

- эш урынындагы тикшерү барышында вазыйфаи затның (вазыйфаи затларының) үз хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, аңа (аларга) карата Россия Федерациясе законына туры китереп чаралар күрү;

- Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган гариза бирүчегә андый чаралар күрелгән көннән башлап 10 календарь көне эчендә язмача хәбәр бирү;

- төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашыру барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (башкарылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндермәү (мондый карарны дәлилле нигезләп, гариза бирүчегә язмача хәбәр җибәрү юлы белән).

Административ регламентка

1 нче кушымта

## Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы



1

2

Ике нөсхәдә кушымталары белән тикшерү актын төзү

Тикшерү акты белән (кушымталары белән) социаль хезмәтләр күрсәтүченең житәкчесен таныштыру

Кушымталарының күчермәләре белән тикшерү актының бер нөсхәсен социаль хезмәтләр күрсәтүченең житәкчесенә бирү яки почта элемтәсе ярдәмендә, кулына бирү турында хәбәрнамә белән, җибәрү

Тикшерү акты күчермәсен прокуратура органына җибәрү (планнан тыш урынга барып тикшерүне прокуратура органы белән килештерү булган очракта)

Уздырылган урынга барып тикшерү турында җаваплы башкаручының тикшерүләрне исәпкә алу журналына (ул булганда) язып куюы

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү

Күрсәтмә бирү (тикшерү акты белән бергә)

Күрсәтмәнең үтәлүе турында социаль хезмәтләр күрсәтүчедән мәгълүмат алу

Күрсәтмәнең үтәлүен (үтәлмәвен) контрольдә тоту буенча планнан тыш тикшерү, тикшерү актын төзү

Күрсәтмә билгеләнгән срокта үтәлмәгән очракта - административ хокук бозу турында беркетмә төзү (РФ АХбКның 19.5 ст. 1 өл.)

РФ АХбКның 19.6, 19.7 ст. белән күздә тотылган административ хокук бозу ачыкланган очракта - административ хокук бозу турында беркетмә төзү

Административ хокук бозу турында беркетмәнең күчермәсен социаль хезмәтләр күрсәтүченең житәкчесенә бирү

Административ хокук бозу турында беркетмәне суд органына җибәрү

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкару дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына
2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының боерыклар өчен бланкында

**Тикшерү үткәрү турында**
**боерык**

**№ ______ "_____" ____________________ ел**

Юридик затны, шәхси эшкуарны ______________________________________тикшерү турында
(план буенча/планнан тыш, документларын/урынга барып)

1. Тикшерү үткәрергә: ______________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

2. Урнашкан урыны: _________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(юридик затның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яки шәхси эшкуарларның чынлыкта эшчәнлек алып бару урыны)

3. Тикшерү үткәрергә вәкаләтле зат(лар) итеп билгеләп куярга: ___________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы)

4. Экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре сыйфатында тикшерү үткәрүгә түбәндәге затларны җәлеп итәргә: __________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(тикшерү үткәрүгә җәлеп ителүче экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфалары һәм (яки) эксперт оешмасының атамасы, аккредитация турындагы таныклык реквизитларын һәм аккредитация турындагы таныклыкны биргән аккредитацияләү органы атамасын күрсәтеп)

5. Бу тикшерүнең түбәндәге максат белән үткәрелүен билгеләргә: ____________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

6. Бу тикшерүнең предметы булып тора:
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

7. Тикшерү үткәрүнең срогы: ____________________________________________________
Тикшерү үткәрергә керешергә:
"____" ________________ 20____ ел. дан башлап
Тикшерүне тәмамларга:
"____" ________________ 20____ ел. дан соңга калмыйча.

8. Тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре: ___________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(тикшерү шуңа туры китереп үткәрелә торган норматив хокукый акт нигезләмәсенә сылтама; тикшерү предметы булып торучы таләпләрне билгели торган (норматив) хокукый актлар нигезләмәләренә сылтама)

9. Тикшерү барышында контроль буенча тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле түбәндәге чараларны үткәрергә: _____________________________________
________________________________________________________________________________

10. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар исемлеге (алар булганда):
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(атамаларын, номерларын һәм аларны кабул итү көннәрен күрсәтеп)

11. Юридик затның, шәхси эшкуарның аларны тапшыруы тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәк булган документлар исемлеге:
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

________________________________________________
________________________________________________ ________________________
(тикшерү үткәрү турында боерык (әмер) чыгарган затның вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары) (мөһер белән расланган имза)

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(боерык (әмер) проектын әзерләгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) һәм вазыйфасы, элемтәгә керү өчен телефоны, электрон адресы (булганда))